КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 1 август г.Казань № 740

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында

Татарстан Республикасының Зәй муниципаль районында «Чаллы– Зәй – Әлмәт» –Гулкин, Төги - Гулкин участогы» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын реконструкцияләү максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының VII бүлегендәге 49 статьясы, VII[1] бүлеге, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279 һәм 281 статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең (алга таба – Татарстанның юл-транспорт идарәсе) Татарстан Республикасының Зәй муниципаль районында «Чаллы – Зәй – Әлмәт» – Гулкин, Төги - Гулкин участогы» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын реконструкцияләү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен дәүләт милкендәге, «Татех» акционер җәмгыятенә арендага бирелгән (алга таба – арендага алучы) Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, «Төги» авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы, «Сепель» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте адресы буенча урнашкан 3 600 кв.метр мәйданлы, 16:19:130305:48 кадастр номерлы җир кишәрлегеннән барлыкка килә торган 82 кв.метр мәйданлы җир кишәрлеген (алга таба – алына торган җир кишәрлеге) алу турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына түбәндәгеләрне законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

10 көн эчендә:

бу карарны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

бу карарны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районындагы Гулкин авыл җирлегенең муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка белдерү) өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгаруны;

бу карарның күчермәләрен арендага алучыга «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Татарстанның юл-транспорт идарәсенә җибәрүне;

алына торган җир кишәрлеге өчен түләү күләме билгеләнгәннән соң 30 көн эчендә, Татарстанның юл-транспорт идарәсе белән берлектә, алына торган җир кишәрлегенә аренда шартнамәсе туктатылу турында килешү (алга таба – килешү) әзерләүне һәм аны арендага алучыга җибәрүне;

килешү төзүне;

алына торган җир кишәрлеге арендасы хокукы туктатылган өчен арендага алучыга акча түләүне;

арендага алучы тарафыннан имза куелган килешү законнар белән билгеләнгән срокта тапшырылмаган очракта, судка тиешле дәгъвалар бирүне.

3. Татарстанның юл-транспорт идарәсенә Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, «Төги» авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы, «Сепель» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте адресы буенча урнашкан торак пунктлар җирләре категориясенең 3 600 кв.метр мәйданлы 16:19:130305:48 кадастр номерлы җир кишәрлегенә һәм Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасының Зәй муниципаль районында «Чаллы – Зәй – Әлмәт» – Гулкин, Төги - Гулкин участогы» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын реконструкцияләү» объекты өчен территорияне планлаштыру һәм ызанлау проектын раслау хакында» 2016 елның 18 ноябрендәге 2621 номерлы карары белән расланган территорияне планлаштыру һәм ызанлау проекты нигезендә тартып алына торган җир кишәрлегенә карата кадастр эшләре үткәрүне тәэмин итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин